Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
Өстәмә профессиональ белем бирүче
дәүләт автоном мәгариф оешмасы
«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты»

# ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН УКУЧЫЛАРНЫ ТӨРКЕМНӘРГӘ БҮЛҮ БУЕНЧА ТӘКЪДИМНӘР

Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының I сыйныфлары өчен

КАЗАН
2016

**ББК 74.268.1 Тат**
**Т23**

**Проект җитәкчесе**
Р.Р. Бәдриева, МҮИ ректоры
**Рецензентлар:**
Сәгъдиева И. Т., ТРМҮИ башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү кафедрасының өлкән мөгаллиме
Манюрова Г. Х., ТРМҮИ мәктәпкәчә яшьтәгеләргә белем бирү лабораториясе мөдире, педагогика фәннәре кандидаты
**Фәнни консультант**
Башлай Э. Х., «Лицей им. Н.И. Лобачевского» ФГАОУ ВО К(П)ФУ, педагог-психолог
**Төзүчеләр:**
Р.Р. Шәмсетдинова, МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доцент, филология фәннәре кандидаты
Г.Н. Мөхәрләмова, МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты
Р.Ф. Фәттахова, МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты
Г.В. Һадиева, МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы

Татар телен өйрәнү өчен укучыларны төркемнәргә бүлү буенча тәкъдимнәр: Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының I сыйныфлары өчен. – Казан, 2016. – 23 б.

© ТРМҮИ, 2016

*Народ в более чистом виде представляют дети.*
*Когда национальное умирает в детях,*
*то это означает начало смерти нации.*
*(Г.Н.Волков, д-р пед. наук, академик РАО)*

## I нче сыйныфка килгән укучыларны татар теле өйрәнү өчен төркемнәргә бүлү буенча тәкъдимнәр

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар телен һәм әдәбиятын укыту процессында әлегә кадәр чишелеш тапмаган мәсьәләләрнең берсе булып, укучыларны төркемнәргә бүлү мәсьәләсе тора. Татар теле һәм әдәбияты рус телендә гомуми белем бирү мәктәпләренең татар төркемнәрендә һәм рус төркемнәрендә укытуның үрнәк программалары, ФДДБС таләпләре буенча төзелгән УМК лар нигезендә укытыла. Ләкин әлегә кадәр укучыларны төркемнәргә бүлү шартлы рәвештә генә башкарылганлыктан, татар төркемнәре күпчелек очракта, тиешле материалны, тиешле югарылыкта үтеп бетә алмый. Шуңа күрә I нче сыйныфка килгән укучыларны татар теле өйрәнү өчен төркемнәргә бүлү – ул телне уңышлы өйрәнүдәге беренче баскыч булып тора.

Мәгълүм булганча, Татарстан Республикасы татар теленә өйрәтү мәктәпкәчә белем бирү оешмаларыннан башлана. Шунлыктан укучының татар телен белү дәрәҗәсен ачыклау, әлеге оешмаларда телгә өйрәтүнең нигезләрен, үзенчәлекләрен исәпкә алуны таләп итә, күчемлелек принцибын алга сөрә.

Дәүләт федераль белем бирү стандартлары таләп иткәнчә, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә

тәрбия һәм белем бирү төрле характердагы барлык эшчәнлеккә нигезләнеп алып барыла: уен, продуктив, танып-белү һ.б. Баланың үсеше өлкәннәр белән аралашу аша бара. Бала татар телен җиңел үзләштерсен өчен аралашуны табигый шартларга якын китереп оештыру мөһим. Мәктәпкәчә яшьтәге оешмаларда телгә өйрәтү күрсәтмә материалга (уенчыклар, рәсемнәр) нигезләнеп оештырыла. Балалар тотып карый алалар, уйныйлар, болар барысы да баланың өйрәнә торган телдә сөйләшәсе килү теләген уятырлык итеп оештырылырга тиеш. Гадәттә, тәрбияче өйрәнә торган телне яхшы белсә, шул телдә актив сөйләшсә, баланың сөйләшәсе, сөйлисе килү теләге туа, шуңа күрә балалар бакчаларында тәрбиячеләр күбрәк үзләре сөйләшә, балалар ияреп кабатлыйлар.

I нче сыйныфка килгән укучыларны татар теле өйрәнү өчен төркемнәргә бүлүне оештырганда, һичшиксез, күчемлелек принцибы сакланырга тиеш. Мәктәпкәчә яшьтәге баланың дөньяны танып-белүе, үсеше уен аша барганлыкны исәпкә алып, укучыларның телне белү дәрәҗәләрен өйрәнү, ачыклауны уен элементлары аша алып бару мөһим.

Татар телендә сөйләшә алу-алмау дәрәҗәсен билгеләү өчен түбәндәге күрсәткечләр, критерийларны тәкъдим итәргә мөмкин.

| № | критерийлар | күрсәткечләр |
|---|---|---|
| 1. | Авазлар әйтелеше | - татар теленә генә хас булган авазларны аерым да, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә эчендә дә дөрес әйтә белү |
| 2. | Сүзлек формалашкан | - әйләнә-тирәдәге предметларны, аларның аерым өлешләрен, күләмнәрен, |

| | | |
|---|---|---|
| | булу | формаларын, төсен, сыйфатларын, хәрәкәтләрен, халәтләрен татарча әйтә белү;<br>- йорт хайваннарын, аларның балаларын белдерүче исемнәрне әйтә белү;<br>- гомуми мәгънәгә ия исемнәрне атый белү;<br>- аерым сүзләргә антонимнар сайлый белү;<br>- сөйләмдә татар теленең этномәдәни лексикасын куллана белү |
| 3. | Сөйләмнең грамматик төзелеше | - сөйләмдә исемнәрне зат формасына куеп куллана белү;<br>- исемнәрнең күплек сан формасын ясый һәм аны сөйләмдә куллана белү;<br>- урын, вакыт мөнәсәбәтләрен белдерә торган килеш кушымчаларын сөйләмдә куллана белү;<br>- сөйләмдә боерык фигыльне куллана белү;<br>- хәзерге, үткән заман формаларын куллана белү;<br>- предметларның урнашкан урыннарын дөрес атый белү;<br>- бәйлекләрне урынлы куллана белү |
| 4. | Тыңлап аңлау (аудирование) | - хайваннар, кошлар турындагы табышмак шигырьләрне аваз ияртемнәренә нигезләнеп аңлый белү;<br>- укытучының телдән сөйләгән хикәясе (әкият, вакыйга) яки укыган тексты буенча куелган сорауларына телдән җавап бирә белү<br>- татар телендәге балалар өчен язылган халык авыз иҗаты әсәрләрен укытучының мимикасы, хәрәкәтләре, интонациясе ярдәмендә аңлый белү; |

| | | |
|---|---|---|
| 5. | Бәйләнешле сөйләм (сөйләшү) | - иптәшләре һәм укытучы белән татар телендә зур булмаган диалог алып бара белү;<br>- хикәя тыңлау барышында ясаган рәсеме турында кыскача гына сөйләп бирә белү;<br>- сәламләү, танышу, үтенеч, рәхмәт әйтү, ризалык белдерү, риза булмау, саубуллашу ситуацияләрендә кулланыла торган сөйләм этикеты әйләнмәләрен куллана белү;<br>- үзе, гаиләсе, уенчыклары турында зур булмаган хикәяләр төзеп сөйли белү;<br>- татар балалар фольклоры үрнәкләрен уен барышына кертеп җибәрә белү |

## Критерийлар буенча контроль-үлчәү материаллары

I. Авазларны әйтүгә диагностика

Биремнәр

[җ]: җә, җа, җи, җы, җө, җү, җу, җе

[һ]: һа,һә, һу, һү, һы, һе, һо, һө

[къ]: ка, ку, ко, кы ак, ук, ок, ык

[гъ]:га, гы, гу, го, ага, ого,угу

[ә]: мә, әм, бә, әб, тә, әт, сә, әс

[ө]: рө, өр, зө, өз, сө, өс, лө, өл

[ү]: мү, өм, үз,зү, үт, тү, үр, рү

[ң]: ңа, ңә, ңы, ңе, ың, эң, иң

II. Түбәндәге авазларга башланган сүзләрне әйт:

[җ]: җәй, җиләк, кәҗә, җырла, җиде...

[һ]: һава, һөнәр, һәм, һәркем ...

[къ]: кара, кул, каш, кыш, кызык ...

[гъ]: Гата, Галия, Газиз, Галим...
[ә]: әни, әби, әти, әтәч, әлифба, Әминә...
[ө]: өй, өрә, өзә, өч, өстәл...
[ү]: үтүк, үлән,үрдәк, үгез...

III. Минем арттан тизәйткечләрне кабатла:

Әрәмәдәге әрем әче.

Кара карга кардан бара, канатларын кага-кага.

Җәйнең ямьле көннәрендә җиләк җыя Җәмилә.

“Һау-һау! Һау-һау! Һау!” – дисең,
Һаман нигә һаулыйсың?”

Абагага бага-бага
Башым бәрдем баганага.

Күпер башында күп күркә, күп күркәгә кирәк күп көрпә.

Авазларны әйтүгә диагностика өчен тәкъдим ителгән күнегүләрне һәр укучы белән аерым башкарырга киңәш итәбез. Укытучы күнегүләрне эшләүне оештыра, ә күзәтүче бәяләп, балларны куеп бара. Бу вакытта төркемдәге башка укучыларга киләсе биремне башкару өчен кирәк булган рәсемнәр өләшенә, алар каршына предметларны игътибар белән карау, өйрәнү бурычы куела.

Бәяләү.

2 балл – укучы татар телендә генә очрый торган авазларны аерым да, иҗек, сүзләр, җөмләләр эчендә дә төгәл әйтә ала. Татар теленә генә хас булган авазлар кергән сүзләрне исендә калдыра һәм атый ала;

1 балл – татар теленә хас булган авазларны әйткәндә төгәлсезлекләр җибәрә, шул авазлар кергән сүзләрне авырлык белән генә исенә төшерә;
0 балл – татар теленә хас авазларны әйтә алмый, сүзләрне исенә төшерә алмый.

## Сүзлек байлыгы формалашуга диагностика

1. *Дидактик уен “Бу нәрсә?”. Тирә-яктагы предметларны һәм аның аерым өлешләрен атый белү.*

Бирем. Предметны һәм аның аерым өлешләрен ата.

Укытучы укучы алдына йорт рәсеме яки аның макетын куя һәм аның өлешләрен атарга куша. Укытучы ул өлешләрне үзе дә күрсәтә ала: “Бу нәрсә?” – дигән сорауны куя (бүлмә: стена, түшәм, ишек, тәрәзә, такта, өстәл, парта, урындык һ.б.)

Бәяләү.
2 балл – укучы предметны һәм аның өлешләрен аерып әйтә;
1 балл – укучы предметны әйтә, ләкин барлык өлешләрне аерып әйтә алмый;
0 балл – укучы предметны да, өлешләрен дә аерып әйтә алмый.

2. *Күләмне, форманы, төсне, нинди дә булса сыйфатны, хәрәкәтне, халәтне атый белү.*

**1 бирем. Дидактик уен “Серле капчык”**. (Капчыкка төрле-төрле уенчыклар (хайваннар, яшелчәләр, җиләк-җимеш һ.б., яки картонга төшерелгән рәсемнәре салынган булырга тиеш).

Укытучы укучыга капчыктан уенчык алырга һәм татар телендә аның зурлыгын, төсен, формасын, сыйфатын атарга тәкъдим итә. Мәсәлән: бу алма. Ул түгәрәк, зур, кызыл, тәмле. Укучы нинди дә бер билгесен әйтмичә калдырса, укытучы сораулар бирә. Мисал өчен, түгәрәк уенчыкның формасын әйтә алмаган укучыга: “Ул шакмаклымы? һ.б. шундый сораулар бирә, ләкин аларда җавап чагылыш табырга тиеш түгел.

**1 бирем. “Кем нишли?”** – хәрәкәтне яки халәтне татарча ата.

Укытучы хәрәкәтне яки халәтне чагылдырган (сикерү, йөгерү, җырлау, ашау, эчү, йоклау, утыру, китап уку, чана шуу, рәсем ясау һ.б.) рәсем яки пиктограммалар күрсәтә, укучы аны татарча атый.

Укытучы фигыльләрне татарча әйтә. Ә укучы рәсемнәр арасыннан шул фигыльгә туры килгәнен сайлап алып күрсәтә.2 балл – укучы барысын да татарча әйтә ала;
1 балл – укытучы ярдәме белән атый;
0 балл – укучы фигыльләрне атый алмый.

*3. “Кире беткән мәче”уены. Сүзләрнең антонимнарын таба белү.*

Бу уенны аерым укучы белән дә, укучылар төркеме белән дә оештырырга мөмкин. Укытучы укучыларны кулындагы уенчык мәче белән таныштыра: Укучылар, бүген безгә кунакка мәче килде, ул бик кире, нәрсә әйтсәң дә киресен әйтергә ярата. Әйдәгез әле, без дә аның белән бергә киресен әйтешле уйныйк. Сез ризамы?

**Бирем**. Укытучы сүзләр әйтә, укучы ул әйткән сүзгә каршы килә торган сүзне таба алырга тиеш:

ак карандаш – кара карандаш
зур туп –кечкенә туп
уң кул – сул кул
авыр китап – җиңел китап
ерак мәктәп – якын мәктәп
матур – ямьсез (матур түгел)
пычрак туфли – чиста туфли
җылы көн – салкын көн
тәмле сөт – тәмсез сөт
тырыш бала – ялкау бала
яхшы малай – начар малай

2 балл – укучы 8–10 сүзтезмәгә антоним табып әйтә алды;
1 балл – укучы 5–7 сүзтезмәгә антоним табып әйтә алды;
0 балл – укучы 0–4 сүзтезмәгә антоним табып әйтә алды.

*4. Йорт хайваннарын, аларның балаларын белдерүче исемнәрне әйтә белү*

**Бирем.** Укытучы йорт хайваны яки йорт кошы төшерелгән рәсемне яки уенчык күрсәтә һәм «Бу нәрсә? Баласын әйт!” – дигән бурыч куя. (Бу эшне аерым укучы белән дә, төркемдә дә эшләтергә мөмкин.)

сыер – бозау
ат – тай (колын)
дуңгыз – дуңгыз баласы
сарык – сарык бәтие
кәҗә – кәҗә бәтие
эт – эт баласы //көчек
песи – песи баласы
каз – каз бәбкәсе
үрдәк – үрдәк бәбкәсе

тавык – чеби

2 балл – укучы 16-20 сүзне атый ала;

1 балл – укучы 10-15 сүзне атый ала;

0 балл – укучы 10 яки аннан да кимрәк сүзне атый ала.

5. *Бер төрдән булган исемнәрне гомумиләштереп бирүче исемнәрне атый белү*.

Укытучы укучыларга предметлар, хайваннар төшерелгән рәсемнәр күрсәтә һәм «Рәсемдә нәрсәләр сурәтләнгән – татарча әйтеп чык. Аларны бер генә сүз белән атап буламы?» – дип сорый.

- Ипи, сөт, май, ит – ашамлыклар.
- Бүре, куян, төлке, аю – кыргый хайваннар.
- Сыер, дуңгыз, сарык, кәҗә – йорт хайваннары.
- Таба, тәлинкә, кашык, чәйнек, чынаяк – савыт-саба.

2 балл – укучы рәсемдәге 10–12 исемне һәм 3–4 гомумиләштерүче сүзне әйтә алды;

1 балл – укучы рәсемдәге 8–9 исемне һәм 2 гомумиләштерүче сүзне әйтә алды;

0 балл – укучы рәсемдәге 8 дән кимрәк исемне һәм 0–1 гомумиләштерүче сүзне әйтә алды.

6. *Сөйләмдә татар теленең этномәдәни лексикасын куллана белү, аларны аңлау.*

**1. бирем.** Укытучы тематик (“Сабантуй”, “Нәүрүз” , “Татар милли  костюмы” һәм башкалар) рәсемнәр күрсәтә һәм укучыларга темалар буенча сүзләр атарга куша:

«Татар халык ашлары» – ...

«Татар халкының бәйрәмнәре» – ...

**2 бирем.** Укучыларга татар халкының милли бәйрәмнәрен чагылдырган рәсемнәр, сюжетлар күрсәтелә һәм аларны атарга, алар турында сөйләргә тәкъдим ителә.

**3 бирем.** «Нәрсә ничек хәрәкәт итә?» Балаларга теге яки бу хайванның ничек хәрәкәт иткәнен күрсәтергә (рәсемнәр, уенчыклар ярдәмендә) һәм шул хәрәкәтне атарга тәкъдим ителә. (Эшне укучылар төркемендә дә, аерым укучы белән дә оештырырга мөмкин).

**4 бирем.** Нинди хайваннар ничек кычкыра? (Аваз ияртемнәре).

Укучылар рәсемнәрдә яки уенчык йорт хайваннарын татарча атыйлар, алар чыгарган аваз ияртемнәрен әйтәләр (мисал өчен, бака – бака-ка-ка-ка, сыер – му-у-у-у, кәҗә – ми-ки-ки-ки, сарык – мә-ә-ә-ә-ә. Үрдәк – бак-бак-бак-бак, әтәч – кикри-күк һ.б.).

2 балл – укучы этномәдәни сүзләрне белә, аларның мәгънәләрен аңлый, сөйләмендә урынлы куллана;

1 балл – укучы сүзләрне белә, ләкин белдергән мәгънәләрен аңлап бетерми, шуңа күрә сөйләмендә кулланмый;

0 балл – укучы этномәдәни лексиканы белми. Аңламый, сөйләмендә кулланмый.

## Сөйләмнең грамматик строен белүгә диагностика

1. *Минем гаиләм. Сөйләмдә зат белән төрләнгән исемнәрне дөрес куллана белү.*

Балалар гаилә фотографияләрен алып киләләр. Аларны, түгәрәк ясап урындыкларга утырталар, уртага тәбәнәк өстәл куела. Һәр бала чиратлап, шул өстәл артына

утыра һәм иптәшләренә үзе алып килгән фоторәсемнәрне күрсәтә һәм гаиләләре турында сөйли, мәсәлән: «Минем исемем Әминә. Миңа 7 яшь. Минем әнием, әтием, бабаем, әбием, апам, энем, песием, этем бар. Әнием – Лилия Мансуровна. Ул мәктәптә эшли. Әтием – Наил Дамирович. Ул заводта эшли...

2 балл – укучы 1 зат белән төрләнгән исемнәрне һәм алмашлыкларны дөрес куллана, профессияләрне атый белә;

1 балл – аерым хаталар күзәтелә;

0 балл – тиешле форма ясый белми.

2. *Исемнәрне күплек формага куя белү.*

Укытучы бер предмет сурәтләнгән рәсем яки уенчык күрсәтә, укучы татарча исемен атый, аннан соң – ике яки күбрәк сандагы шул ук предмет төшкән рәсем яки уенчыклар күрсәтә, укучы аларны күплек сан формасында атый, мәсәлән: эт – этләр, алма – алмалар, йорт – йортлар, песи – песиләр һ.б.

2 балл – укучы күплек сан кушымчасын калын һәм нечкә сүзләргә дөрес ялгый;

1 балл – кайвакыт хаталар күзәтелә;

0 балл – укучы исемнәрне күплек санда куллана белми.

3. *Боерык фигыль формасын сөйләмдә урынлы куллана белү.*

«Цирк» исемле сюжетлы-рольле уен. Укытучы укучыны цирк дрессировщигы итеп билгели. Ул уенчыкларга боерыклар бирә, мәсәлән: Эт, син йөгер.

Песи, бас. Куян, утыр. Кәҗә, кара. Сарык, кил. Бүре, кит. Аю, кычкыр. Төлке, бир һ.б.

2балл – укучы боерык фигыль формасын белә, сөйләмендә урынлы куллана.

1 балл – аерым очракларда хаталар ясый, исем белән бәйләп китә алмый.

0 балл – боерык фигыль формасын ясый һәм сөйләмендә куллана белми.

4. *Хәзерге, үткән заман формаларын куллана белү.*

Укучыга сюжетлы рәсемнәр күрсәтелә. Беренче рәсемдә бала өстәл артында ашап утыра. Икенчесендә – бала өстәл яныннан китеп бара, бушаган савыт-сабаны юарга куярга алып бара. Укытучы аңлата: рәсемдә син үзең сурәтләнгән дип уйла һәм минем сорауларыма җавап бир:

- Син нишлисең?
- Мин көндезге аш ашыйм.
- Син нишләдең?
- Мин көндезге аш ашадым.

Башка төр эшне күрсәткән рәсемнәр дә булырга мөмкин.

2 балл – укучы фигыль формасын сөйләмендә дөрес куллана.

1 балл – укучы фигыль формасын кулланганда сөйләмендә кайбер хаталар җибәрә.

0 балл – укучы сөйләмендә фигыльнең тиешле формасын куллана белми.

5. *Бәйлекләрне сөйләмдә урынлы куллана белү. «Әбиемнең йомгагы югалган» – дидактик уен.*

Укытучы укучыга мөрәҗәгать итеп: «Әбиең сиңа шарф бәйләп утыра. Аның йомгагы тәгәрәп китә һәм югала. Ул синнән ярдәм сорап нәрсә әйтер?» (Йомгак диван астында (шкаф артында, өстәл янында ...) түгелме?)

Укытучы укучыга рәсемнәр күрсәтә, яки уенчык хайваннарны бәйлекләр белән әйтә торган итеп урнаштыра: песи өстәл астында, песи шкаф өстендә, песи эт белән, песи кыз янында, песи әнисе кебек ак һ.б.

2 балл – укучы сөйләмендә 3–4 бәйлекне урынлы куллана;
1 балл – укучы сөйләмендә 1–2 бәйлекне урынлы куллана;
0 балл – укучы сөйләмендә 0–1 бәйлекне куллана.

## Тыңлап аңлауга диагностика

1. *Укучының хайваннар, кошлар бөҗәкләр турындагы табышмакларны, шигырьләрне аваз ияртемнәренә нигезләнеп аңлауларын ачыклау.*

Укытучы текстны үзе укый, укучы өстәлдә яткан уенчыклар арасыннан тиешлесен сайлап алырга һәм татар телендәге атамасын әйтергә тиеш.

1. Үз өстенә җәй дә, кыш та
Энәле күлмәк кия.
Шулай да аны әнкәсе
“Йомшагым” диеп сөя. (Керпе)
2. Асрамый да умарта,
Балны бик, бик ярата.
Кышын сөя йокыны,
Язгача тормый ята. (Аю)
3. Аллы-гөлле очкалак,
Оча, гөлләр кочкалап. (Күбәләк)

4. Тызлый да бызлый,
Үпкән җире сызлый. (Бал корты)
5. Аллы-гөлле чәчәкләрне
Кетер-кетер ашый ул.
Шуннан ап-ак сөт ясап,
Көн дә безгә ташый ул. (Сыер)
6. Иртән бик иртә тора,
Матур итеп кычкыра. (Әтәч)
7. Канаты бар – оча алмый,
Аягы бар – йөзә алмый. (Тавык)
8. Яшел палас өстендә
Сары йомгак тәгәри. (Каз бәбкәсе//чеби)
9. Чырр,чырр,чырр, ди ул,
Канат белән җырлый ул.
Аяк белән тыңлый ул. (Чикерткә)
10. Мырк-мырк мырылы,
Бик каты икән борыны. (Дуңгыз)
11. Кикрикүк! Безне йокыдан уята бик иртүк. (Әтәч)
12. Бә-ә, бә-ә, диләр. Башка бер ни әйтмиләр. (Бәтиләр)

2 балл – укучы беренче тапкыр тыңлаганда ук дөрес уенчыкны таба һәм атый (8–10 атама).

1 балл – укучы беренче тапкыр тыңлаганда ук дөрес уенчыкны таба һәм атый (5–7 атама).

0 балл – укучы беренче тапкыр тыңлаганда ук дөрес уенчыкны таба һәм атый (4 тән кимрәк атама).

*2. Укытучының сөйләгәнен аңлауны ачыклау:*

- укытучы укучыларга таныш әкиятне (мисал өчен, “Теремкәй”, “Шалкан”, “Күмәч”) укый. Укучылар

әкиятнең эчтәлеге буенча укытучының сорауларына кыска гына җөмләләр белән татар телендә җавап бирергә тиешләр.
2 балл – укучы татар телендә кыска гына җөмләләр төзи белә, дөрес җавап бирә
1 балл – укучының җаваплары куелган сорауларга бер генә яклы (төрле)
0 балл – укучы татар телендә куелган сорауга җавап бирә алмый.

Тыңлаган текстның эчтәлегендә чагылыш тапкан предметларны рәсемдә чагылдыра белү.
2 балл – укучы 4–5 сүзнең эчтәлеген рәсемдә дөрес чагылдыра һәм татарча атый;
1 балл – укучы 2–3 сүзнең эчтәлеген рәсемдә дөрес чагылдыра һәм татарча атый;
0 балл – укучы 0–1 сүзнең эчтәлеген рәсемдә дөрес чагылдыра һәм татарча атый.

## Бәйләнешле сөйләмгә диагностика

1. *Зур булмаган диалог алып бара алу.*

**«Уенчыклар кибете» дип аталган сюжетлы-рольле уен.**

Аерым темалар буенча диалогик сөйләмгә контроль: «Кыргый хайваннар», «Размер» (зур, кечкенә), «Сыйфаты» (йомшак, каты, матур, ямьсез), «Төсе», «Формасы», «Саны».

Мисал.

*Сатучы*. Исәнмесез, сезгә нәрсә кирәк?

*Укучы*. Миңа бер зур йомшак ак аю кирәк.

*Сатучы*. Аю 5 сум тора.

*Укучы*. Менә монда 5 сум.

*Сатучы*. Алыгыз.

*Укучы*. Рәхмәт. Сау булыгыз!

*Сатучы*. Сау булыгыз!

2 балл – татар телендә иркен аралаша;

1 балл – иркен аралаша алмый, кайвакыт рус теленә күчә.

0 балл – татар телендә диалог алып бара алмый.

*2. Сөйләм этикетыннан тиешле урында файдалана алу.*

**«Кунакка барабыз» дип аталган сюжетлы-рольле уен.**

Йорт хуҗалары–укучылар һәм кунаклар–укучылар диалог алып баралар (исәнләшү, өстәл артына чакыру, саубуллашу):

- Керергә ярыймы?
- Керегез! Әйдә өстәл артына рәхим ит! Салат аша. Бәлеш аша. Чәй эч.
- Салат бик тәмле. Бәлеш бик тәмле. Чәй баллы. Рәхмәт!
- Исәнлеккә!
- Сау бул!
- Сау бул!

2 балл – бала сөйләм этикетын сөйләмендә урынлы һәм иркен куллана.

1 балл – диалогик сөйләм укытучы ярдәме белән алып барыла.

0 балл – сөйләм этикетын сөйләмендә куллана белми.

*3. Кыска хикәяләр төзи белү.*

Аерым темага монологик сөйләм төзүгә контроль, мисал өчен, «Минем этем (песием)» Минем этем бар. Исеме – Акбай. Ул ак, йомшак, кечкенә, матур. Акбай ит, сөт, сөяк ярата. Мин Акбай белән урамда уйныйм.

2 балл – сөйләм төзек, эзлекле, 4–5 фразадан тора;

1 балл – сөйләм кыска, эзлеклелек һәм бәйләнеш юк, 2–3 фразадан тора;

0 балл – укучының сөйләме 1–2 фразадан тора, җөмлә оештыра алмый.

*4. Татар балалар фольклоры үрнәкләрен аңлау һәм андагы хәрәкәтләрне башкару.*

Укучының һәр биремне башкара алуы өчен куелган баллар таблицага куела һәм берләштерелә. Шулай итеп һәр критерий буенча баллар чыгарыла:

1 критерий: Авазларны әйтү

| № | Исеме, фамилиясе | [ж] | [h] | [къ] | [гъ] | [ә] | [ө] | [ү] | [ң] | баллар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | |

2 критерий: Сүзлек формалашу

| № | Исеме, фамилиясе | Тирә-яктагы предметларны, аларның өлешләрен атый белү | Зурлыгын, формасын, төсен, сыйфатын, хәрәкәтен, халәтен атый белү | Хайваннарны, аларның балаларын атый белү | Гомумиләштереп әйтә белү | Сүзләргә антонимнар таба белү | Этномәдәни лексиканы белү | Баллар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |

3 критерий: Сөйләмнең грамматик төзелеше

| № | Исеме, фамилиясе | Зат белән төрләнеш | Күплек сан | Боерык фигыль Хикәя фигыль | бәйлекләр | баллар |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| | | | | | | |

4 критерий: Аудирование

| № | Исеме, фамилиясе | Шигырь-табышмакларны аваз ияртемнәренә нигезләнеп аңлау | Күплек сан | Боерык фигыль Хикәя фигыль | бәйлекләр | баллар |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| | | | | | | |

5 критерий: Бәйләнешле сөйләм

| № | Исеме, фамилиясе | Укытучы сөйләгәнне тыңлау, әчтәлектә чагылыш тапкан предметларны ясау һәм сөйләү | Зур булмаган диалог төзү | Сөйләм этикетына караган сүзләрне урынлы куллана белү | Кыска гына хикәя төзи алу | Балалар фольклорын уеннарда аңлау | баллар |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| | | | | | | | |

Татар телендә сөйләшә алу күнекмәләре формалашу дәрәҗәсе

| № | Исеме, фамилиясе | 1 критерий | 2 критерий | 3 критерий | 4 критерий | 5 критерий | баллар | дәрәҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |

Татар телендә сөйләшә алу күнекмәләре формалашу дәрәҗәләре

Югары дәрәҗә – 47–54 балл
Уртача дәрәҗә – 27–46 балл
Түбән дәрәҗә – 0–26 балл

Баллардан чыгып укучыларны төркемнәргә бүлү башкарыла. 47–54 балл җыйган укучылар татар төркемнәренә билгеләнә. Бу төркемгә 35–46 балл җыйган укучыларны да кушарга мөмкин (әгәр төркемнәргә бүлгәндә, укучыларның саннары кискен аерылып торса). Мондый очракта әлеге укучылар аерым игътибар үзәгендә булып, эш төрләрен оештырганда исәпкә алынырга тиеш. 35 тән дә түбәнрәк балл җыйган укучылар рус төркемнәренә билгеләнә. Диагностиканы һәр теманы үткәннән соң яки һәр чирек азагында алып барырга һәм баллар аша укучыларның эшләренә нәтиҗә ясап барырга киңәш ителә.

Укучының тел өйрәнүгә әзерлегендә гаиләдәге тел ситуациясе, анда телләр өйрәнүгә булган мөнәсәбәт тә зур роль уйный. Шуңа күрә, әти-әниләрне интервьюер буларак, анкета тутыруларын сорарга һәм ул анкеталарны өйрәнеп, анализлап нәтиҗәләр ясау да укучыларның алга

таба тел өйрәнүдәге мөмкинлекләренә диагностика ясарга мөмкин.

Диагностика үткәрү методикасы өлешчә балаларның үсеш дәрәҗәсен билгеләү юнәлешендә тикшерүләр алып бара торган iPIPS системасына нигезләнеп эшләнде һәм ул тәкъдим характерында .

Диагностика үткәрүне камилләштерү буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне “Мәгарифне үстерү институты”ның татар теле һәм әдәбияты кафедрасына җибәрүегезне сорыйбыз.

## Файдаланылган әдәбият


1. Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү: программа, методик киңәшләр, диагностика / авт.-төз.: З.М. Зарипова, Р.С. Исаева, Р.Г. Кидрячева һ.б. – Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013. – 112 б.

2. Зиннурова Ф.М. Үз илемдә, үз телемдә. – Казан: Мәгариф, 2009.

3. Колчанова С.С. Стартовая диагностика первоклассников как основа планирования индивидуальных образовательных траекторий // Региональное образование XXI века: проблемы и перспективы. – 2012. – №1. – С.11–14.

4. Ковалева Г.С., Даниленко И.В., Ермакова И.В., Нурминская Н.В., Гапонова Н.В., Давыдова Е.И. (2011). О первоклассниках (по результатам исследований готовности первоклассников к обучению в школе). URL: http://www.centeroko.ru/public.htm

5. Карданова Е.Ю. Стартовая диагностика детей на входе в начальную школу и оценка их прогресса в течение первого года обучения: международное исследование iPIPS. Центр мониторинга качества образования Института образования НИУ Высшая школа экономики. http://ioe.hse.ru/monitoring/

# ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН УКУЧЫЛАРНЫ ТӨРКЕМНӘРГӘ БҮЛҮ БУЕНЧА ТӘКЪДИМНӘР

Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының I сыйныфлары өчен

Корректура, компьютерная верстка, техническое редактирование
Гиниятуллина Р. С., Некратова А. В.

Форм.бум. 60х84 $^{1}/_{16}$. Гарнитура Times.
Усл.печ.л. 1,5.

Оригинал-макет подготовлен в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
www.irort.ru, irort2011@gmail.com